РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Буа шәһәре

19 август 2020 ел № 6-56

Буа муниципаль районы Советының 2015 елның 13 февралендә кабул ителгән 9-45 номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турында Нигезләмә хакында» гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 20 статьясы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрүне тәртипкә салу максатларында, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. ТР Буа муниципаль районы Советының 2015 елның 13 февралендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турында Нигезләмә хакында» 9-45 номерлы карары белән расланган (28.04.2017 ел, №9-19 карар редакциясендә), Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнарында конкурс нигезендә биләп торучы муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлегенә (2 нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. а) 1 бүлектән 3 бүлекчәне төшереп калдырырга;

б) 2 бүлектән 3 бүлекчәне төшереп калдырырга;

в) 7 бүлектән 2 бүлекчәне төшереп калдырырга;

г) 9 бүлектән 2 бүлекчәне төшереп калдырырга;

2. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнарында конкурс нигезендә биләп торган муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеген яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта):

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Буа муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе М.М. Юнысовага йөкләргә.

Буа муниципаль районы башлыгы урынбасары,
Совет рәисе урынбасары И.Ф. Еремеев

«Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районы
Советының
«19» август 2020елның
6-56 номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнарында конкурс нигезендә биләп торган муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеге**

1 булек. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы Аппаратында муниципаль хезмәт вазыйфалары

1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары:

- Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе.

2. Муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары:

- Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы аппаратының юридик бүлеге башлыгы;
- Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы аппаратының җирле үзидарә органнары белән эшләү бүлеге башлыгы;
- Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы аппаратының массакүләм мәгълүмат чаралары, җәмәгатьчелек, хатлар һәм үтәлешен контрольдә тоту бүлеге башлыгы;
- Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы аппаратының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге башлыгы;
- Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы аппаратының гомуми бүлеге башлыгы.

2 бүлек. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетында муниципаль хезмәт вазыйфалары

1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары:

- Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе;
- Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары;
- Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары;
- Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының Эшләр идарәчесе.

2. Муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары:

- Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлеге башлыгы;
- Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының мәгълүматлаштыру һәм мәгълүматны яклау бүлеге башлыгы;
- Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура бүлеге башлыгы;
- Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыгы бүлеге башлыгы;
- Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге начальнигы;
- Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль сатып алулар бүлеге башлыгы;
- Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының архив бүлеге җитәкчесе;
- Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының Гражданлык хәле актларын теркәү бүлеге башлыгы;
- Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте бүлеге башлыгы.

3 бүлек. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәре Башкарма комитетында муниципаль хезмәт вазыйфалары

1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары:

- Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе.

4 бүлек. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесендә муниципаль хезмәт вазыйфалары

1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары:

- «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесе рәисе;
- «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесенең бюджет бүлеге башлыгы урынбасары.

2. Муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары:

- «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесенең исәп-хисап бүлеге башлыгы;
- «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесенең фаразлау һәм анализлау бүлеге башлыгы.

5 бүлек. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Контроль-хисап палатасы» муниципаль казна учреждениесендә муниципаль хезмәт вазыйфалары

1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары:

- «Буа муниципаль районының Контроль-хисап палатасы» муниципаль казна учреждениесе рәисе урынбасары.

6 бүлек. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы» муниципаль казна учреждениесендә муниципаль хезмәт вазыйфалары

1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары:

- «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы» муниципаль казна учреждениесе рәисе.

7 бүлек. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесендә муниципаль хезмәт вазыйфалары

1. Муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары:

- Буа муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы.

8 бүлек. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы мәдәният идарәсе» муниципаль казна учреждениесендә муниципаль хезмәт вазыйфалары

1. Муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары:

- «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы мәдәният идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы.

9 бүлек. «Буа муниципаль районының яшьләр, спорт һәм туризм идарәсе» муниципаль казна учреждениесендә муниципаль хезмәт вазыйфалары

1. Муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары:

- «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының яшьләр, спорт һәм туризм идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы.